КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 2 июнь г.Казань № 678

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларын раслау турында» 2013 ел, 27 декабрь, 1071 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларын раслау турында» 2013 ел, 27 декабрь, 1071 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 28 июль, 547 нче; 2016 ел, 9 август, 547 нче; 2018 ел, 25 гыйнвар, 39 нчы; 2018 ел, 4 апрель, 206 нчы; 2018 ел, 29 сентябрь, 874 нче; 2018 ел, 10 декабрь, 1099 нчы; 2019 ел, 9 сентябрь, 805 нче; 2020 ел, 3 декабрь, 1091 нче; 2021 ел, 19 июль, 593 нче; 2022 ел, 3 июнь, 519 нчы; 2022 ел, 3 октябрь, 1059 нчы, 2022 ел, 15 ноябрь, 1217 нче, 2023 ел, 11 февраль, 141 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлектә:

1.2 бүлекчәнең 2 нче таблицасына искәрмәләрнең тугызынчы абзацында «2020 елның 14 июлендәге 1190 номерлы» сүзләрен «2023 елның 13 февралендәге 318 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

1.9.6 бүлекчәнең 15 нче таблицасындагы “Түбән Кама” милли паркы” (федераль әһәмияттәге) юлының 2 нче графасында:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«файдалы казылмаларны, җир асты суларын разведкалау һәм чыгару, моңа милли паркларны саклауны һәм алардан файдалануны тәэмин итү, рекреация зоналары чикләрендә рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру, хуҗалык билгеләнешендәге зоналар һәм Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) саклау зоналары өчен кирәк эчәргә яраклы, хуҗалык-көнкүреш һәм техник су белән тәэмин итү максатларында җир асты суларын разведкалаудан һәм чыгарудан тыш;»;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әгәр мондый эшчәнлек милли паркны саклауны һәм файдалануны тәэмин итү, аның рекреацион зоналары, хуҗалык билгеләнешендәге зоналар һәм Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) саклау зоналары чикләрендә рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру һәм милли парк территориясендә яшәүче гражданнарның тормышын тәэмин итү белән бәйле очраклардан тыш, туфрак катламын һәм тау токымнарын бозуга китерә торган эшчәнлек;»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«су объектлары торышына йогынты ясый торган тискәре процессларны үстерүгә китерә торган эшчәнлек;»;

алтынчы абзацта «магистраль» сүзен «автомобиль» сүзенә, «эшләве» сүзен «саклауны һәм файдалануны тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга;

II бүлекнең 35 нче таблицасының 2.3 - 2.5 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «2.3. | Яшеренү урыны | тәэмин ителеш дәрәҗәсе, бер яшеренгән кешегә бүлмәләрнең идән мәйданы кв.метр | исәп-хисап күрсәткечләренең мәгънәсе СП 88.13330.2022 «СНиП II-11-77* Гражданлык оборонасы саклау корылмалары» 5.2.1 пункты нигезендә кабул ителде |
| | | бүлмәнең эчке күләме, бер яшеренгән кешегә куб.метр | мәгънәсе СП 88.13330.2022 «СНиП II-11-77* Гражданлык оборонасы саклау корылмалары» 5.2.1 пункты нигезендә кабул ителде |
| | | җәяүлеләр өчен үтемлелек, метр | мәгънәсе СП 88.13330.2022 «СНиП II-11-77* Гражданлык оборонасы саклау корылмалары» 4.13 пункты нигезендә кабул ителде |
| 2.4. | Радиациягә каршы ышыкланулар | тәэмин ителеш дәрәҗәсе, бер яшеренгән кешегә бүлмәләрнең идән мәйданы кв.метр | исәп-хисап күрсәткечләренең мәгънәсе СП 88.13330.2022 «СНиП II-11-77* Гражданлык оборонасы саклау корылмалары» 6.1.2, 6.1.4 пунктлар нигезендә кабул ителде |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | җәяүлеләр өчен үтемлелек, метр | мәгънәсе СП 88.13330.2022 «СНиП II-11-77* Гражданлык оборонасы саклау корылмалары» 4.13 пункты нигезендә кабул ителде |
| | | транспорт белән барып җитү, километр | мәгънәсе СП 88.13330.2022 «СНиП II-11-77* Гражданлык оборонасы саклау корылмалары» 4.13 пункты нигезендә кабул ителде |
| 2.5 | Ышыклану урыннары | тәэмин ителеш дәрәҗәсе, бер яшеренгән кешегә бүлмәләрнең идән мәйданы кв.метр | мәгънәсе СП 88.13330.2022 «СНиП II-11-77* Гражданлык оборонасы саклау корылмалары» таләпләре нигезендә кабул ителде |
| | | җәяүлеләр өчен үтемлелек, метр | мәгънәсе СП 88.13330.2022 «СНиП II-11-77* Гражданлык оборонасы саклау корылмалары» таләпләре нигезендә кабул ителде. |

2. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә торган 1 пунктындагы дүртенче – унберенче абзацларыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин